**СОВЕТ МАТЮШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МАТЮШИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

**2026 елның «24» марты** **24 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегендә 2026 елда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартандагы 25-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Законына, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турындагы 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Кодексына таянып, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда яллаучы вәкил (эш бирүче) карары буенча Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.
2. Әлеге карарны Матюшино авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп баруны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Матюшино
авыл җирлеге Советы рәисе** **Н.И.Миннуллина**